ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы карары**

**2019 ел 19 июнь** **№ 249**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләү турында Нигезләмә раслау турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексы нигезендә, Арча муниципаль районы Уставы белән җитәкчелек итеп, Арча район Советы **карар чыгарды**:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләү турында Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://arsk.tatarstan.ru адресы буенча Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советы аппарат җитәкчесе Р.Н.Галимуллинга йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г.Нуриев

Расланды
Татарстан Республикасы Арча
муниципаль районы башкарма
комитетының
2019 ел, «19» июнь , 249
нче карары белән

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен**
**мәҗбүри дәүләт иминиятләү турында**
**Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта муниципаль хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминиятләве буенча очракларны, түләү тәртибен һәм күләмен (алга таба – мәҗбүри дәүләт иминиятләве) билгели.

2. Мәҗбүри дәүләт иминиятләве муниципаль хезмәткәр вазыйфага билгеләнгән көннән алып муниципаль хезмәткәр вазыйфадан азат ителгән көнгәчә муниципаль хезмәт башкаруның барлык вакытына муниципаль хезмәткәрләрнең тормышы һәм сәламәтлегенә карый.

3. Мәҗбүри дәүләт иминиятләве буенча иминиятләштерелүче булып җирле үзидарә органнары һәм муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт үткән башка муниципаль органнар (алга таба – иминиятләштерелүчеләр).

4. Мәҗбүри дәүләт иминиятләве буенча иминиятләүчеләр (алга таба – иминиятләүчеләр) булып мәҗбүри дәүләт иминиятләве башкаруга лицензияләре булган иминиятләү оешмалары булырга мөмкин.

Иминиятләүчеләр сайлау дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар алу, эш, хезмәт күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә башкарыла.

5. Иминиятләү килешүе иминиятләүче һәм иминиятләштерелүче арасында иминиятләштерелүче зат (файда күрүче) файдасына бер календар елга Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә тәүлегенә 24 сәгать иминият яклавы белән төзелә.

Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында каралган иминият очраклары өчен иминиятләү килешүендә иминиятләштерелүче тарафыннан файда күрүчеләр күрсәтелә.

Иминиятләштерелүче тарафыннан иминиятләү килешүендә файда күрүчеләр сыйфатында мәҗбүри рәвештә күрсәтелергә тиеш:

иминиятләштерелгән затның вафат булган көненә аның белән рәсми никахта торган ире (хатыны);

иминиятләштерелгән затның әти-әнисе, иминиятләштерелгән затның әби-бабайсы – әти-әнисе булмаган очракта, әгәр алар аны өч елдан да ким булмаган дәвердә тәрбияләп, карап торган булсалар;

иминиятләштерелгән затның 18 яшькә җитмәгән яки 18 яшьтән өлкәнрәк балалары, әгәр алар 18 яшь тулганчы инвалид булган булсалар, шулай ук оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына бәйсез рәвештә белем бирү оешмаларында укучылар – укып бетергәнче, тик 23 яшь тулганчы;

иминиятләштерелгән затның опекага алган кешеләре.

Файда алучылар иминиятләү килешүендә гражданлык хезмәткәре китергән мәгълүмат буенча, иминиятләүче билгеләгән тәртиптә күрсәтелә. Иминиятләү килешүендә файда алучыларны күрсәтү кирәк булмаган очракта файда алучылар булып гражданлык законнары белән билгеләнгән тәртиптә иминиятләштерелгән затның варислары таныла.

Муниципаль хезмәткәрне иминиятләү килешүенең гамәлдә булу вакыты чыкканчы муниципаль хезмәттән азат итү иминиятләү килешүен әлеге муниципаль хезмәткәргә карата муниципаль хезмәттән азат ителгән көннән гамәлдән чыгара. Әлеге нигез буенча муниципаль хезмәткәргә карата иминиятләү килешүен вакытыннан алда өзгән очракта иминиятләүче и иминиятләштерелүчегә әлеге муниципаль хезмәткәрне иминиятләү белән бәйле рәвештә түләнгән акчаны, әлеге муниципаль хезмәткәргә карата иминиятләү килешүе гамәлдә булу вакытының калган өлешенә пропорциональ рәвештә әлеге Нигезләмәнең 12 пункты белән билгеләнгән тәртиптә кире кайтара.

Иминиятләү очраклары булып санала:

1) муниципаль хезмәт башкару вакытында, шулай ук муниципаль хезмәт башкарган вакытта алынган имгәнү, җәрәхәтләнү яки авыру нәтиҗәсендә муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң 1 ел эчендә иминиятләштерелгән затның вафат булуы;

2) муниципаль хезмәт башкару вакытында, шулай ук муниципаль хезмәт башкарган вакытта алынган имгәнү, җәрәхәтләнү яки авыру нәтиҗәсендә муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң 1 ел эчендә иминиятләштерелгән затка инвалидлык бирелү;

3) муниципаль хезмәт башкарган вакытта иминиятләштерелгән затның имгәнүе, җәрәхәтләнүе;

4) иминиятләштерелгән затның медицина нәтиҗәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча муниципаль хезмәткәрне ул биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итү һәм муниципаль хезмәттән чыгару белән эшкә алучы вәкиле инициативасы буенча хезмәт килешүен өзү өчен нигез булучы һәм инвалидлык билгеләү белән бәйле булмаган авыру алуы.

8. Иминиятләштерелүчеләргә (файда алучыларга) түләнә торган иминиятләү суммалары күләме муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата окладын (алга таба – оклад) тәшкил итүче биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы һәм классны чин өчен өстәмә түләү нигезендә билгеләнә.

9. Иминият очраклары барлыкка килгән очракта иминият суммалары түбәндәге күләмдә түләнә:

1) иминиятләштерелгән зат муниципаль хезмәт башкарган вакытта, шулай ук муниципаль хезмәт башкарган вакытта имгәнү, җәрәхәтләнү яки авыру сәбәпле муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел дәвамында вафат булган очракта – 26,25 оклад. Күрсәтелгән иминият суммасы файда күрүчеләргә бертигез өлешләрдә түләнә;

2) иминиятләштерелгән затка муниципаль хезмәт башкарган вакытта, шулай ук муниципаль хезмәт башкарган вакытта имгәнү, җәрәхәтләнү яки авыру сәбәпле муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел дәвамында инвалидлык билгеләнгән очракта:

I төркем инвалидына – 17,5 оклад;

II төркем инвалидына – 12,25 оклад;

III төркем инвалидына – 10,5 оклад;

3) иминиятләштерелгән зат муниципаль хезмәт башкарган вакытта авыр имгәнгән яисә җәрәхәтләнгән очракта – 7 оклад, җиңелчә имгәнгән яисә җәрәхәтләнгән очракта – 1,75 оклад түләнә. Тиешле иминият суммасы түләнә торган имгәнүләрне һәм җәрәхәтләрне авыр яисә җиңелчә төргә кертү «Хәрби хезмәткәрләр, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарының гади һәм башлык составы затлары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының хезмәткәрләре гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» 1998 елның 28 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән, авыр яисә җиңелчә төргә кертелгән имгәнүләр (яраланулар, җәрәхәтләр, контузияләр) исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла;

4) иминиятләштерелгән затның медицина нәтиҗәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча муниципаль хезмәткәрне ул биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итү һәм муниципаль хезмәттән чыгару белән эшкә алучы вәкиле инициативасы буенча хезмәт килешүен өзү өчен нигез булучы һәм инвалидлык билгеләү белән бәйле булмаган авыру алуы очрагында – 8,75 оклад.

Муниципаль хезмәт башкарган вакытта яки муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел вакыт узганчы медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениедә кабат аныклау узган вакытта иминиятләштерелгән затка инвалидлык төркеме күтәрелсә, иминият суммасы күләме яңа билгеләнгән инвалидлык төркеме буенча окладлар саны белән элеккеге инвалидлык төркеме буенча тиеш булган окладлар саны аермасы тәшкил иткән суммага арттырыла.

Әгәр иминиятләштерелгән затка иминият очрагына бәйле иминият суммасы түләнгән булса, әмма иминият очрагы кергән көннән алып ел дәвамында һәм шуңа турыдан-туры бәйле рәвештә аның сәламәтлеге какшаса яки ул вафат булса, элек түләнгән иминият суммасын (иминият суммаларын) чигереп, өстәмә иминият түләве башкарыла.

Һәр иминиятләштерелгән зат өчен түләнә торган иминият премиясенең күләме иминият килешүе белән билгеләнә һәм иминиятләштерелгән затның иминият килешүен төзү вакытына билгеләнгән окладының 8,75 процентыннан арта алмый.

10. Иминиятләүче мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе буенча иминият суммасын түләүдән азат ителә, әгәр иминият очрагы:

1) иминиятләштерелгән затның суд тарафыннан билгеләнгән тәртиптә иҗтимагый куркыныч дип танылган гамәл кылуы аркасында булса;

2) иминиятләштерелгән затның алкоголь, наркотик яки агулы матдәләр белән исерүенә турыдан-туры бәйле булса, һәм ул суд тарафыннан расланса;

3) иминиятләштерелгән затның үз сәламәтлегенә белә торып зыян китерүе яки иминияәләштерелгән затның үзенә кул салуы аркасында булса, һәм ул суд тарафыннан расланса.

Иминиятләштерелгән зат суд тарафыннан расланган үз-үзенә кул салуга җиткерү нәтиҗәсендә вафат булса, иминиятләүче иминият суммасын түләүдән азат ителми.

Иминият суммасын түләүдән баш тарту турында карар иминиятләүче тарафыннан кабул ителә һәм иминиятләштерелгән затка (файда алучыга) һәм иминиятләүчегә, күрсәтелгән баш тарту сәбәпләрен мәҗбүри рәвештә дәлилле нигезләп, иминият суммасын түләүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вакыт эчендә язмача хәбәр ителә.

11. Иминият түләүләре иминиятләнгән затның (файда алучының) гаризасы һәм иминиятләнүче тарафыннан тапшырылган, иминият очрагы барлыкка килүне раслый торган документлар нигезендә иминиятләүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Иминият түләвен гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен кирәкле документларның исемлеге, аларны тапшыру һәм карау тәртибе иминият килешүе белән билгеләнә.

Иминиятләүче тарафыннан иминият суммалары иминиятләнгән затларга (файда алучыларга) сумнарда түләнергә тиешле суммаларны иминият килешүендә билгеләнгән ысул белән күчереп түләнә.

Иминият суммаларын түләү күрсәтелгән түләү турында карар кабул итү өчен кирәкле документларны алган көннән соң 10 көн эчендә башкарыла.

12. Иминият килешүенең гамәлдә булу вакыты дәвамында иминиятләштерелгән затларның оклад күләмнәре, шулай ук аларның саны үзгәрсә, күрсәтелгән хәлләргә бәйле рәвештә алынып бетмәгән яки артык алынган иминият кертемнәре суммалары өстәмә түләнергә яисә кире кайтарылырга тиеш. Иминият килешүен төзегән яклар килешүе буенча күрсәтелгән суммалар иминият килешүенең чираттагы гамәлдә булу чорында иминият кертемнәре күләмнәрен билгеләгәндә исәпкә алынырга мөмкин.

Иминият кертемнәрен иминиятләүче тарафыннан кертүнең дәвамлылыгы иминият килешүе белән билгеләнә.

13. Мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүенә чыгымнарны финанслау муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.